| МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

ПРИКАЗ БОЕРЫК

08.04.2019 г.Казань № 246-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясының 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган Вазыйфаи затларны һәм Россия Федерациясе гражданнарын дәүләт сере белән эш итүгә кертү тәртибе турында күрсәтмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

3. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 27 мартындагы 135-осн номерлы боерыгы.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр в.б. Ә.Н. Бәдертдинов

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2019
елның 08.04. № 246-осн
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасының «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәтенең баш вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

эшләр белән идарә итүче;

финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлек бүлеге башлыгы;

дәүләт урман реестры, урманнардан файдалану һәм урманнарны тәртипкә китерү бүлеге башлыгы;

аренда мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы;

урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү бүлеге башлыгы;

дәүләт контрольлеге һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы.

2. Татарстан Республикасының «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча сектор мөдире.

3. Татарстан Республикасының «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре:

әйдәп баручы консультант (мобильләштерелгән эш һәм дәүләт серен яклау буенча белгеч).